ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның «12» декабреннән № 364

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының мәгариф оешмаларына фәнче-педагог һәм педагог-тәрбияче вазыйфасына эшкә алынган педагогик белем алган югары уку йортын тәмамлаучыларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләрне билгеләү тәртибе һәм шартлары турында**

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы мәгариф системасын үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 11 декабрендәге 325 номерлы карары нигезендә Яңа Чишмә муниципаль районы мәгариф оешмаларында педагогик составны кадрлар белән тәэмин итүне яхшырту һәм яшь белгечләрне җәлеп итү өчен шартлар тудыру максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының мәгариф оешмаларына фәнче-педагог һәм педагог-тәрбияче вазыйфасына эшкә алынган педагогик белем алган югары уку йортын тәмамлаучыларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләрне билгеләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне расларга.

2. Югары педагогик белем алган һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының мәгариф оешмаларына фәнче-педагог һәм педагог-тәрбияче вазыйфасына эшкә алынган югары уку йортын тәмамлаучыларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләрне билгеләү тәртибе һәм шартлары

буенча комиссия составын (1 нче кушымта) һәм яшь белгечкә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләүгә гариза формасын (2 нче кушымта) расларга.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына ел саен чираттагы финанс елына район бюджетын формалаштырганда әлеге карарны гамәлгә ашыру өчен акча каралга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http:// pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның «12» декабреннән
364 номерлы карары белән
расланган

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының мәгариф оешмаларына фәнче-педагог һәм педагог-тәрбияче вазыйфасына эшкә алынган педагогик белем алган югары уку йортын тәмамлаучыларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләрне билгеләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы мәгариф оешмаларына эшкә алынган югары һөнәри белем алган яшь белгечләргә - педагогларга бер тапкыр түләнә торган түләүләр билгеләү тәртибен һәм шартларын билгели (алга таба - бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) муниципаль районның мәгариф оешмаларында яшь белгечләргә - педагогларга матди ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыру чараларын күздә тота.

Әлеге Нигезләмәне куллану максатларында:

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы мәгариф оешмасына (алга таба - мәгариф оешмасы) төп эш урыны буенча укуын тәмамлаган елда кабул ителгән, көндезге уку формасында югары һөнәри белем бирү мәгариф оешмасын тәмамлаучы 30 яшькә кадәрге (30 яшьне кертеп) яшь белгеч (алга таба - яшь белгеч).

2. Әлеге Нигезләмә нигезендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру 2023 елдан төзелгән хезмәт шартнамәләре буенча эшкә алынган яшь белгечләргә карата башкарыла.

2.1. Яшь белгеч статусы белем бирү оешмасына эшкә кергәннән соң өч ел дәвамында гамәлдә була. Әлеге статус түбәндәге очракларда озайтыла (өч елга кадәр):

1) хәрби хезмәткә чакыру яисә аны алыштыручы альтернатив граждан хезмәтенә җибәрү;

3. бала карау буенча аңа өч яшь тулганчы ял бирү. Бер тапкыр түләнә торган акчалата түләү яшь белгечкә белем бирү оешмасында эшләгән һәр уку елын өчен бирелә.

Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүнең күләме:

Беренче уку елы өчен - 50 000 сум;

Икенче уку елы өчен - 50 000 сум;

Өченче уку елы өчен - 50 000 сум.

4. Һәр уку елы тәмамланганнан соң яшь белгеч «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесенә әлеге Нигезләмәгә кушымтада бирелгән форма буенча бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне күчерү турында гариза бирә.

5. Әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән гаризага түбәндәге документлар (документларның күчермәләре)теркәлә:

әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән затның Россия Федерациясе гражданы паспорты:

белеме турында вкладыш белән документ;

әлеге нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән затның яшәү урынын (тору урынын) раслаучы документ;

мәгариф оешмасы белән төзелгән хезмәт килешүе;

салым түләүченең идентификацион номеры (ИНН):

кредит оешмасында ачылган банк счеты номеры.

Гариза һәм аңа беркетелгән документлар мөрәҗәгать итүче вәкиле аша тапшырыла икән, шулай ук мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәлләрне башкаруга вәкаләтләрен раслаучы документ тапшырыла. Гариза бирүче исеменнән гамәлләрне башкаруга вәкаләтләрне раслаучы документ сыйфатында Россия

Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе бирелә.

6. Нотариаль расланмаган документларның күчермәләре оригиналны күрсәтеп тәкъдим ителергә тиеш. Документлар кабул итүче вазыйфаи зат тарафыннан документларның күчермәләре оригиналлары белән чагыштырыла, раслана, шуннан соң оригиналлар яшь белгечкә кире кайтарыла.

7. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесенең (алга таба – мәгариф бүлеге) документлар кабул итүче белгече тәкъдим ителгән документларның әлеге Нигезләмәнең 4 һәм 5 пунктларына туры килү-килмәвенә тикшерү үткәрә.

Гариза бирүче әлеге Нигезләмәнең 4 һәм 5 пунктларында каралган барлык документларны да тапшырмаган очракта, документлар кабул итүне гамәлгә ашыручы мәгариф бүлеге белгече аларны кабул итүдән баш тарта. Баш тарту сәбәбен күрсәтеп документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар гариза бирүчегә аларны тапшырганнан соң 2 эш көне эчендә язмача җибәрелә. Гариза ( 2 нче кушымта) һәм документлар гариза бирүче тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 4 һәм 5 пунктлары нигезендә тапшырылган очракта, алардан хисап эше формалаштырыла һәм мәгариф бүлегендә төзелгән комиссия каравына тапшырыла.

8. Әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән затка бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү турындагы документларны карау формалаштырылуы һәм эшләү тәртибе Мәгариф бүлеге тарафыннан билгеләнгән комиссия (1 нче кушымта) тарафыннан башкарыла.

9. Мәгариф бүлеге комиссиясе әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән затка бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүдән баш тарту турында кабул ителгән карар турында карар кабул ителгән көннән 30 көн эчендә язмача хәбәр итә.

10. Әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән затка бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында карар мәгариф бүлегенә әлеге

Нигезләмәнең 4 һәм 5 пунктларында каралган документлар керү датасы буенча хронологик тәртиптә кабул ителә.

11. Әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән затка бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне бирүдән баш тарту турында карар кабул итүгә түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән затның бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү хокукы булмау

2) - гариза бирүче тарафыннан дөрес булмаган белешмәләр бирү;

12. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән затка бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турындагы карар мәгариф бүлеге боерыгы белән раслана, аның проекты тиешле комиссия секретаре тарафыннан әзерләнә, анда күрсәтелә:

әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы булган очракта);

туган көне, ае, елы һәм урыны (ил, республика, край, өлкә, торак пункт, шул исәптән авыл, бистә, шәһәр, район);

әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән затның биләгән вазыйфасы, эш урыны (мәгариф оешмасы);

бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү күләме.

13. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән затка, кредит оешмасында ачылган банк счетына күчерү юлы белән, мәгариф бүлеге боерыгы рәсмиләштерелгәннән соң 10 эш көне эчендә башкарыла.

14. Әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән затка бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне бирүдән баш тарту судта шикаять ителергә мөмкин.

Әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән затка бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне бирүдән баш тарту Нигезләмәнең 4 һәм 5 пунктларында каралган документларны кабат тапшыру өчен киртә булып тора.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның «12» декабреннән
364 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының мәгариф оешмаларына фәнче-педагог һәм педагог-тәрбияче вазыйфасына эшкә алынган педагогик белем алган югары уку йортын тәмамлаучыларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләрне билгеләү тәртибе һәм шартлары буенча комиссия составы

Комиссия рәисе:

| | | |
|---|---|---|
| Еронтьев Александр Леонидович | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары (социаль мәсьәләләр буенча) |

Комиссия рәисе урынбасары:

| | | |
|---|---|---|
| Бутина Анна Ивановна | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгы |

Комиссия секретаре:

| | | |
|---|---|---|
| Нурхаметова Ләйсән Рифхать кызы | - | «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесе мәгълүмати-методик бүлеге мөдире, Бөтенроссия мәгариф профсоюзының Яңа Чишмә территориаль оешмасы председателе |

Комиссия әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Әхмәтшина Ләйсән Әзгать кызы | - | - «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» |

|  |  |  |
|---|---|---|
|  |  | муниципаль учреждениесе мәгълүмати-методик бүлегенең мәктәпкәчә белем бирү буенча методисты; |
| Улитин Александр Борисович | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгы урынбасары |

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның «12» декабреннән
364 номерлы карарына
2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесенә

______________________________

Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме

Яшәү урыны адресы (тору урыннары);

______________________________

Паспорт сериясе ______________________

______________________________

Бирү датасы______________________

Кем тарафыннан бирелгән ______________________

Туган датасы ______________________

Югары һөнәри белеме турында документы

______________________________

документның исеме, сериясе, номеры

## Гариза

### яшь белгечкә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү турында

Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләвегезне сорыйм______________________________________ (беренче тулы уку елы, икенче тулы уку елы, өченче тулы уку елы).

Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне банк картасына күчерергә ______________________________ (банк реквизитларын, карта номерын күрсәтергә).

Белем бирү оешмасында булган шәхси мәгълүматларымны (фамилиям, исемем, әтисемем, адресым, туган көнем, түләүләр күләме һ.б.) социаль ярдәм чараларына хокукларымны гамәлгә ашыру максатыннан белешмәләрнең конфиденциальлеген саклау шарты белән өченче затларга тапшырырга рөхсәт итәм. Минем шәхси мәгълүматларымны ___________ елга кадәр кулланырга рөхсәт итәм.

Мин «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесенә язмача гариза бирү юлы белән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгымны кире ала алуымны беләм.

«____»____________ 20     ел                                        ____________________

имза